СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский", Мамадышский район, Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«19» февраля 2020 г.

Карар
№1-50

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2016 елның өченче мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2016 елның өченче мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 ел №2-15, 15.05.2017ел №1-20, 28.07.2017ел №3-21, 14.11.2017ел №2-25, 05.06.2018ел №2-31, 13.08.2018 ел №2-33, 20.11.2018 ел №3-37, 14.12.2018 ел №2-38, 21.03.2019 ел №1-40, 18.09.2019 ел №3-45 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.6 пунктының 13 абзацына түбәндәге редакциядәге җөмлә өстәргә:
««2020 елның 1 октябреннән соң муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында каралган авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре вазифага 2020 елның 1 октябренә кадәр билгеләнгән муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42

статьясындагы 4 өлеше нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда каралган тиешле квалификация таләпләренә туры килә торган муниципаль хезмәткәрләргә карата кулланылмыйлар»;

1.2. 8.1 пунктындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга:
а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция), эшкә алучының Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алынган вәкиле рөхсәтеннән башка) катнашу;

в) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советында, Муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) «Идарә итү һәм ревизия комиссиясе органнарында, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен (акционер)түләүсез нигездә тапшыру, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче»;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

2.1.шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә»;

1.3. 12.3 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.4. 22.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.3.Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә»;

1.5. 23.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23.9. Әлеге Нигезләмәнең 7, 8, 9 һәм 22 статьяларында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, ялда булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча производство вакыты кертелми.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге
Советы рәисе / Гыйззәтулина В.А /

СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» «КРАСНОГОРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИНН 1626001027